КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 июль г.Казань № 574

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат бирүчеләр турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2024 елның 19 мартындагы 329 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат бирүчеләр исемлеген расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты - әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру өчен мәгълүмат бирергә вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы - Татарстан Республикасы буенча әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында эш координаторы.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2024 елның 19 мартындагы 329 номерлы карары һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат җибәрүчеләр исемлеге белән белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүматны урнаштырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына йөкләргә.

5. Әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат җиткерүчеләр исемлегенең 1 - 10 пунктлары 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 17 июль, 574 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат бирүчеләр исемлеге

| Т/с | Мәгълүмат составы | Мәгълүмат җиткерүче | Мәгълүмат тапшыру һәм урнаштыру сроклары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү проектын (алга таба - бетерү проекты) эшләү турында мәгълүмат, шул исәптән:<br>тупланган зыян объектын юкка чыгарырга планлаштырыла торган объект турында;<br>бетерү проектын эшләүгә эшләр заказчысы турында;<br>сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында бетерү проектын эшләүгә эшләр сатып алуны урнаштыру турында (сатып алу датасы һәм номеры) яисә бетерү проектын эшләү буенча эшләрнең бердәнбер башкаручысын билгеләү турында;<br>бетерү проектын эшләүгә контракт турында (контракт датасы һәм номеры, подрядчы исеме, салым түләүченең идентификация номеры, контрактны үтәү сроклары);<br>бетерү проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | тиешле мәгълүмат кергән көннән алып 10 эш көне дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | турында (үткәрү сроклары);<br>бетерү проектына дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен яисә проект документациясенә һәм инженер эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу турында (үткәрү сроклары, экспертизаны озайту турында белешмәләр, бәяләмә номеры һәм датасы);<br>смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү турында бәяләмә алу турында (үткәрү сроклары, тикшерүне гамәлгә ашыручы исеме, экспертизаны озайту турында белешмәләр, бәяләмәнең номеры һәм датасы);<br>бетерү проектын раслау турында (бетерү эшләре заказчысы акты датасы һәм номеры);<br>Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты дәүләт программасында тупланган зыян объектын бетерү чаралары барлыгы турында (дәүләт программасы реквизитлары) | | |
| 2. | Тупланган зыян объектын бетерү эшләрен башкару турында мәгълүмат, шул исәптән:<br>бердәм мәгълүмат системасында тупланган зыян объектын бетерү эшләрен сатып алуны урнаштыру турында (сатып алу датасы һәм номеры) яисә тупланган зыян объектын юкка чыгару эшләрен башкаручының бердәнбер күләмен билгеләү турында;<br>тупланган зыян объектын юкка чыгару эшләрен уздыруга контракт турында (контракт датасы һәм номеры, подрядчы исеме, салым түләүченең идентификация номеры, эшләрне төгәлләү һәм контрактны үтәү сроклары);<br>төзелеш контроленә контракт турында (контракт датасы, номеры, подрядчы исеме, салым түләүченең идентификация | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | тиешле мәгълүмат кергән көннән алып 10 эш көне дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | номеры, контрактны үтәү сроклары) (мәгълүмат булган очракта урнаштырыла);<br>әзерлек этабын уздыруның статусы турында (эшләрне уздыру сроклары, статусы, әзерлек проценты) (мәгълүмат булган очракта урнаштырыла);<br>техник этапны уздыруның статусы турында (эшләрне уздыру сроклары, статусы, әзерлек проценты) (мәгълүмат булган очракта урнаштырыла);<br>биологик этапны уздыруның статусы турында (эшләрне уздыру сроклары, статусы, әзерлек проценты) (мәгълүмат булган очракта урнаштырыла);<br>әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү барышын күзәтү нәтиҗәләре турында;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү барышын күзәтүче федераль башкарма хакимият органының бәяләмәсе турында (бәяләмәнең номеры һәм датасы);<br>тупланган зыян объектында әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне кабул итү хакындагы акт турында (акт номеры һәм датасы);<br>әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында (Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы боерыгының датасы һәм номеры) | | |
| 3. | «Аучылык турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча | ел саен, хисап елыннан соң килә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 32 һәм 36 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла торган аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт мониторингы нәтиҗәләре турында мәгълүмат (хайваннар дөньясының һәр объектына карата урнаштырыла), шул исәптән мәгълүмат:<br>аучылык ресурсларының саны динамикасы турында;<br>аучылык ресурсларына кертелгән тояклы хайваннарны аулау күләмнәре турында;<br>аучылык ресурсларына кертелгән кыйммәтле хайваннарны (бүреләрдән тыш) тартып алу күләмнәре турында;<br>аучылык ресурсларына кертелгән кошларны (төрләр төркемнәре) аулау күләмнәре турында;<br>бүреләрне тартып алу күләмнәре турында;<br>аюларны тартып алу күләмнәре турында;<br>аучылык ресурсларына кертелгән тояклы хайваннарның ундырышлылыгы турында;<br>аучылык ресурсларына кертелгән хайваннарның ачыкланган авырулары турында;<br>аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге элементларының торышы турында (аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге класслары буенча) | дәүләт комитеты | торган елның 15 сентябреннән дә соңга калмыйча |
| 4. | «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» Федераль законның 4 статьясы нигезендә алып барыла торган махсус сакланылучы табигать территорияләренең дәүләт кадастрыннан мәгълүмат (һәр махсус саклана торган табигать территориясенә карата урнаштырыла) | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | ел саен, 1 июльгә кадәр |
| 5. | Комплекслы планнарны гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүмат (расланган комплекслы план булу шарты белән | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары | хисап елыннан соң килә торган елның |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | мәгълүмат җиткерүче тарафыннан урнаштырыла), шул исәптән:<br>әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектлардагы, шул исәптән коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларында чыгарып ташлауларны киметүгә юнәлдерелгән комплекслы планнар чараларын, атмосфера һавасының сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыру турында белешмәләр, әлеге чараларны башкару срокларын, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын, федераль башкарма хакимият органнарының, республика башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның күрсәтелгән чараларын үтәгән өчен җаваплылыгын, шулай ук бу чыгарып ташлауларны кимету күрсәткечләренең фактта ирешелгән күрсәткечләрен күрсәтеп;<br>атмосфера һавасын пычратуның җыелма исәпләүләре нигезендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр (радиоактив матдәләрдән тыш) чыгарып ташлауларны квоталау буенча эксперимент үткәрүгә җаваплы республика башкарма хакимият органнары турында белешмәләр;<br>атмосфера һавасын пычратуның җыелма исәпләүләре нигезендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр (радиоактив матдәләрдән тыш) чыгарып ташлауларны квоталау буенча экспериментта һәр катнашучы өчен гамәлгә ашырыла торган компенсация чаралары исемлеге; | министрлыгы | 30 декабреннән дә соңга калмыйча |
| 6. | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законның 29.1 статьясындагы 8 пунктында күрсәтелгән мондый объектлар исемлеген төзү һәм үзгәртү тәртибе нигезендә 2019 | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министр- | каты коммуналь калдыкларны урнаштыру объекты |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | елның 1 гыйнварына кадәр файдалануга кертелгән һәм Россия Федерациясе законнарында каралган документлары булмаган каты коммуналь калдыкларны урнаштыру объектлары турында мәгълүмат (һәр объектка карата урнаштырыла) https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=LAW&n=466001&dst=824 | лыгы | турында мәгълүмат үзгәргән көннән алып 10 эш көне дәвамында |
| 7. | Мәгълүмат (төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасының һәр объектына карата урнаштырыла):<br>төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасының эксперт комиссиясе эшли башлау турында хәбәрнамәнең реквизитлары хакында;<br>төбәк дәрәҗәсенәге дәүләт экология экспертизасын уздыру сроклары турында;<br>төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасы эксперт комиссиясенең оештыру утырышын уздыру датасы турында;<br>эксперт комиссиясенең оештыру утырышын уздыру урыны турында | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | агымдагы елның 1 июненнән һәм 30 декабреннән дә соңга калмыйча |
| 8. | Дәүләт экология экспертизасын уздыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат (төбәк дәрәҗәсендәге һәр дәүләт экология экспертизасы объектына карата урнаштырыла), шул исәптән:<br>төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасының номеры һәм бәяләмәсе датасы;<br>төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасының бирелгән бәяләмәләре реестрына кертү датасы;<br>төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе турында язма; | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен раслаган көннән алып 3 эш көне дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасы объекты исеме;<br>төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасына материаллар биргән заказчы турында белешмәләр;<br>төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын уздырган орган турында белешмәләр;<br>төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын уздырган органның боерыгы яисә карары реквизитлары, датасын һәм номерын күрсәтеп, дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен раслау турында;<br>дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсен раслаган очракта гамәлдә булу вакытын күрсәтеп, төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасы уздыру нәтиҗәсе;<br>төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен мондый суд карарын юкка чыгару турында төбәк дәрәсенҗәдәге объектларга дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен тану хакында законлы көченә кергән суд карары турында белешмәләр (законлы көченә кергән суд актының реквизитларын күрсәтеп) | | |
| 9. | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законның 32 статьясы нигезендә әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыру тәртибендә билгеләнә торган иҗтимагый фикер алышулар үткәрү һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат (планлаштырыла торган (ниятләнгән) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең һәр объектына карата урнаштырыла) | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында мәгълүмат өчен – җәмәгатьчелек танышу өчен җәмәгать фикер алышуы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | объектының һәркем өчен аңлаешлы булуын тәэмин итү датасыннан исәпләнә торган планлаштырыла торган иҗтимагый фикер алышу көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча; иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында мәгълүмат өчен – иҗтимагый фикер алышулар уздырылганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча |
| 10. | Кабул итү пунктының исемен дә кертеп, эшкәртелгән терекөмеш лампаларны кабул итү пунктлары турында мәгълүмат; кабул итү пунктының адресы (эшкәртелгән терекөмеш лампаларны кабул итү пунктына карата урнаштырыла) | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | I һәм II класслы куркыныч калдыклар белән эш итүне исәпкә алу һәм тикшереп тору федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат җиткерүче теркәл- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | гәннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, шулай ук I һәм II класслы куркыныч калдыклар белән эш итүне исәпкә алу һәм тикшереп тору федераль дәүләт мәгълүмат системасында шундый тәэмин итүче урнаштырылган мәгълүмат үзгәргән көннән алып 10 эш көне дәвамында |
| 11. | Җитештерү һәм куллану калдыкларын, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты территориясендә барлыкка килә торган каты коммуналь калдыкларны җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру, күмү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты территориясендә барлыкка килә торган каты коммуналь калдыкларны һәм аны үстерү юнәлешләре турында мәгълүмат | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасын раслаган, калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасына үзгәрешләр керткән көннән алып 10 көн эчендә |
| 12. | Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитнең (экологик мәгълүмат) торышы, шул исәптән табигать мохите компонентлары, табигый экологик системалар, аларда бара | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | хисап аеннан соң килә торган айның 10 сентябренә кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | торган процесслар, күренешләр, табигать һәм антропоген факторлар йогынтысында әйләнә-тирә мохит торышының үзгәрешләрен бәяләү һәм фаразлау турында аналитик мәгълүмат | | |